**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-АФОНКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423103, Мордва Афонькәсе авылы, Цаплин урамы, 19 нчы йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru

**№129** **19 июнь 2024 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге депутатларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайлап куелган җирле үзидарә вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларына, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларына, депутатларга, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлап куелган җирле үзидарә органнары әгъзаларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларына айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру турында» 2024 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге депутатларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайлап куелган җирле үзидарә вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы карарына (җирлек Советының 2018 елның 24 августындагы № 88, 2018 елның 13 ноябрендәге № 92; 2020 елның 22 октябрендәге № 8; 2022 елның 17 ноябрендәге №78, 2023 елның 31 гыйнварындагы № 86 карары белән кертелгән үзгәрешләр

белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 3 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең хезмәт хакы күләме 13323 сум тәшкил итә»;

1.2. «Айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм түләү күләме» 7 нче кушымтасында 1 нче пунктны бәян итәргә:

«1. Мордва Афонькәсе авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә премиядән тыш ай саен акчалата бүләкләүләр дә түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи хезмәт хакының 41 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.

1.3. 3 нче кушымта «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен» кушымтага ярашлы рәвештә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
Советы рәисе, башлыгы                                        А.И.Митяев

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
Советы карарына кушымта
________________2024 №_____

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 18260 |